МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 ноябрь 2016 ел № М 387

Шәһәр Хакименең 2009 елның 30 мартындагы 135 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы белән расланган муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 1 августындагы 415 номерлы боерыгы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2009 елның 30 мартындагы 135 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 1 февралендәге М 30 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Яр Чаллы шәһәре гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планы гражданнар оборонасын алып бару һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларның күләмен, оештырылуын, тәэмин итү тәртибен, ысулларын һәм срокларын билгели.»;

2) 14 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Мәгълүмат җыю һәм алмашу Башкарма комитет тарафыннан, шулай ук билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән һәм I һәм II класс куркынычлы җитештерү объектларын, югары

куркынычлы гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3) 15 пунктның 3 пунктчасындагы «а» абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын эвакуацияләү чараларын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч зоналардан куркынычсыз районнарга эвакуацияләү чараларын планлаштыру, әзерләү һәм үткәрүне оештыру, шулай ук үз эшчәнлеген сугыш вакытында дәвам итүче оешмалар хезмәткәрләрен һәм куркыныч янаган зоналарда гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешма хезмәткәрләрен урнаштыру;»;

4) 15 пунктның 8 пунктчасындагы «б» абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару районнарында һәм билгеләнгән тәртиптә янгынга каршы формированиеләрнең гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән оешмаларда янгыннарны сүндерүне оештыру, аларның гамәлләрен планлаштыру һәм янгыннан саклауның башка төрләре белән хезмәттәшлекне оештыру;».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев